**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**Мамадыш муниципаль районы**
**Түбән Шүләнгер авыл җирлеге составына керүче**
**Түбән Шүләнгер авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«08» ноябрь 2019 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә принциплары турында»гы 6 октябрь, 2003 ел, 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 28 июль, 2004 ел, 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче маддәсе, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләнгер авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 ст., Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләнгер авыл җирлегенең Түбән Шүләнгер авылында 2019 елның 8 ноябрь узган үзара салым акчаларын куллану һәм кертү буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләнгер авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы: Түбән Шүләнгер авылы, Совет урамы ягына баручы юлны вакташ җәеп ремонтлау; (сатып алу, ташу, вак таш җәю, түләү буенча эш килешүе).

« ӘЙЕ» «ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 127 кеше кертелгән;
халык җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 116 кеше;
Халык җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» 116 кеше тавыш бирде;
«Юк» 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлегенең Түбән Шүләңгер авылында узган халык җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип таныйрга.

2. Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлегенең Түбән Шүләңгер авылында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип таныйрга:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы: Түбән Шүләңгер авылы, Совет урамы ягына баручы юлны вакташ җәеп ремонтлау; (сатып алу, ташу, вак таш җәю, түләү буенча эш килешүе).

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Башлык ,
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Шүләңгер авыл җирлеге
Советы рәисе

(имза) (имзаның расшифровкасы)